**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОКАДЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Советская ул, 51, с.Утыз Имян ,423109

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 51, Утыз Имән авылы, 423109

тел.(884396) 2-01-45 факс (884396) 2-01-45 email: Nkad.Cmn@tatar.ru

**№ 26** **20 август 2025 ел**

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампаларны җыю урыннары турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 24.06.1998 № 89-ФЗ, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 10.01.2002 № 7-ФЗ, «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 23.11.2009 № 261-ФЗ, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү һәм куллану калдыкларын тиешенчә булмаган җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Кади авыл җирлегендә яшәүче терекөмешле лампаларны кулланучыларда эшкәртелгән терекөмешле лампаларның туплану урынын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Утыз Имән авылы, Совет ур., 51 йорт.
2. Чирмешән муниципаль районының Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында кулланылган терекөмешле лампалар туплау урыннарының урнашуы турында, шулай ук мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүматны урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.
3. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампаларны җыюны оештыру тәртибе турында» 2017 елның 29 маендагы 12 номерлы карарын;

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампаларны җыюны оештыру тәртибе турында» 2017 елның 29 маендагы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 18 июлендәге 22 номерлы карары.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Кади авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесе М.М.Әминов